**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
18.07.2019

КАРАР
ПР-153

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарының көзге урып-җыю сезонына әзерлеге турында Нигезләмәне раслау турында

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыру, үсемлекчелек тармагын үстерү максатларында стимуллаштыру Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Раслагра:

1.1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарының көзге урып-җыю сезонына әзерлеге турында Нигезләмәне 1 санлы кушымта нигезендә раслагра;

1.2. комиссия составы, №2 кушымта нигезендә;

1.3. Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарының көзге урып-җыю сезонына әзерлеген карау комиссиясе составын 3 санлы кушымта нигезендә раслагра,;

2. Актаныш муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 27 июль ПР-183 санлы «Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең көзге урып-җыю сезонына әзерлеге Нигезләмәсен раслау турындагы” карарын үз көчен югалтты дип табарга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л. Р. Сираевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе И.Ш.Бариев

Кушымта № 1.
Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның __18__ июле ПР-153 санлы карары белән расланган
____________И. Ш. Бариев

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарының көзге урып-җыю сезонына әзерлеге турында Нигезләмә.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын бүләкләү һөнәри осталыгын, хезмәт нәтиҗәлелеген арттыру, урып-җыюда катнашучы хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында башкарыла.

1.2. Бүләкләү тантанасын Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты оештыра.

1.3. Бүләкләү акчалата формада башкарыла.

1.4. Финанслау район бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Бүләкләү максатлары

2.1. Бүләкләү түбәндәге максатларда үткәрелә:

- Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы продукциясен арттыруга стимуллаштыру;
- Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең хуҗалык-финанс хәлен яхшырту ;
- башкарылган эш өчен җаваплылыкны арттыру.

## 3. Бүләкләү тантанасында катнашучылар

3.1. Бүләкләүгә Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең яхшы күрсәткечләргә ирешкән комбайнерлары лаек була.

3.2. Бүләкләү экипажлы комбайнны карау нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

3.3. Тикшерүдә 95 экипаж катнаша. Комбайнчылар исемлеге кушымта итеп бирелә.

## 4. Бүләкләү тәртибе

4.1. Җиңүчеләрне бүләкләү составы ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган комиссия карары нигезендә башкарыла.

4.2. Җиңүчеләрне бүләкләү комиссия карары буенча, бер экипажга 1000 сум күләмендә башкарыла.

## 5. Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын сайлап алуны уздыру механизмы

5.1. Комбайннарны карау һәм комбайнчылар экипажларын бүләкләү тәртибе. Тикшерү ел саен район зоналары буенча үткәрелә.

5.2. Комбайннарның көзге урып-җыю сезонына әзерлеге

- комбайнны 2019 елгы урып-җыю сезонына әзерләү;
- теоретик белемнәр (тест)
- комбайнны эшкә әзерләү һәм эш процессы
-эш барышында куркынычсызлык техникасын белү
- профессиональ сыйфатлар.

## 6. Бүләкләү өчен авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарын билгеләү буенча Комиссия

6.1. Җиңүчеләрне бүләкләү составы ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган комиссия карары нигезендә башкарыла. ( 2 нче кушымта)

6.2. Комиссия үз эшендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарын көзге урып-җыю сезонына әзерләү комиссиясе турындагы №3 кушымта белән расланган Нигезләмәгә таяна;

## 7. Йомгак ясау һәм бүләкләү оештыру

7.1. Комиссия беркетмәсе нигезендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башкарма комитеты җитәкчесенең Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын бүләкләүгә акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсе проекты әзерләнә.

7.2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе проектында түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш::
- Бүләкләнүчеләрнең исем-фамилиясе;
- эшләүче вазыйфа (һөнәр);
- эш урыны;
- акчалата бүләк суммасы;

Финанс чыганагы, Актаныш муниципаль районы муниципаль программасының конкрет чарасын күрсәтеп, бюджет классификациясе коды.

7.3. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайнчыларын бүләкләүгә, аларның дөрес һәм вакытында кучерелүенә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылышын контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башкара.

2 нче номерлы кушымта

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән расланган

И. Ш. Бариев

Комиссия рәисе:
УСХиП начальнигы Мирхәйдәров А. А..

Рәис урынбасары:
авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең механикалаштыру буенча консультанты Н.А.Сәлимгәрәев

Комиссияәгъзалары:

УСХиПның ФЭО начальнигы-Мухаметдинов Д. З.,
Россельхозцентр Актаныш филиалы начальнигы - Сарваров А. А.
Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең Актаныш филиалы башлыгы Хәкимов И. М.,

3 нче номерлы кушымта

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән расланган
_______________И. Ш. Бариев

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарының көзге урып-җыю сезонына әзерлек комиссиясе турында Нигезләмә

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарының көзге урып - җыю сезонына әзерлек комиссиясе составы (алга таба - конкурс) һәм комиссия турында нигезләмә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карары (алга таба-комиссия) белән расланa.

Үз эшчәнлегендә комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

Комиссия башкара:

1) конкурста катнашучыларның объектив бәясен;

2) конкурста җиңүчеләрне билгели.

Комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Комиссия рәисе:

- комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;
- комиссиянең чираттагы утырышы көн тәртибе проектын формалаштыра;
- комиссия утырышында рәислек итә;
- комиссия эшен һәм әлеге Нигезләмә нигезендә документлар әзерләүне оештыра;;
- комиссия эше барышында әзерләнгән документларның сыйфаты өчен җавап бирә.

Комиссия рәисе булмаган чорда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссия сәркатибе

- комиссия утырышларына материаллар әзерләүне тәэмин итә;
- комиссия әгъзаларына комиссиянең чираттагы утырышы һәм комиссиянең чираттагы утырышларының көн тәртибе турында утырыш үткәрү датасына кадәр 5 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә;
- комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара.

3. Комиссия әгъзалары хокуклы:

- Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертү;
- кабул ителгән комиссия карары белән килешмәгән очракта, комиссия беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кертелергә тиешле үз аерым фикереңне белдерергә.

Әгәр Бердәм комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 50 проценты катнашса, ул хокуклы санала.

Комиссия конкурста катнашучыларны бәяли. Конкурста катнашучыларның йомгаклау бәяләүләре нигезендә Комиссия иң күп балл җыйган җиңүчеләрне билгели.

Комиссия карарлары аның утырышында катнашучы комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.